# МӘКТӘП ДУЛКЫНЫНДА

*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№ 10, май, 2024 ел*




## Бабайларым турында хатирәләр

Минем карт бабам - Гатауллин Хәкимулла өч сугышта катнашкан. Гражданнар сугышына киткәндә аңа 18 яшь кенә булган. Аннан исән-имин әйләнеп кайткан. Аннары фин сугышында булган. 1941 нче елда Бөек Ватан сугышына китә. Анда яраланып госпитальдә ята. Терелгәч, тагын сугышка керә. Германиягә кадәр барып җитеп, 1945 нче елда җиңү белән туган авылына әйләнеп кайта. Төрле эшләрдә хезмәт куя. Картайгач, авылыбызда мулла булып тора. 87 яшендә вафат була.

Карт бабамның улы Хәкимуллин Хәмбәл 18 яшендә армия сафларына алына. Севастопольдә сугыш җимерекләрен бетереп, тәртип урнаштыруда катнаша. 1947 нче елда армиядән кайта. Колхозда шофер булып эшли. Бик күп медальләргә, мактау кәгазьләренә ия була. 1987 нче елда озак һәм каты авырудан вафат була.

Мин бабаларым белән бик горурланам. Тарихны белергә кирәк!

**Шигапова Диләрә, 5 нче сыйныф укучысы**

## Батырлар даны мәңгелек

8 май көнне безнең авылыбызда Җиңү бәйрәменә багышланган митинг узды. Анда мәктәп укучылары, тыл ветераннары, укытучылар һәм килгән кунаклар катнашты. Митингны мәктәбебезнең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Гөлфия Зөфәр кызы алып барды.Митинг укучылар белән берлектә әзерләнгән бәйрәм концерты белән дәвам итте. Матур җырлар, әдәби-музыкаль монтаж чакырылган кунакларның күңеленә бик хуш килде. Бәйрәмдә авылыбызның паркында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган һәйкәлгә венок салдылар һәм алар истәлегенә бер минут тынлык булды. Бәйрәмдә авыл советы рәисе Искәндәр Хәсбиуллин,мәктәп директоры Хәмит Хәкимҗанов чыгышлары тыңланды. Соңыннан тыл ветераннары чәй эстәленә чакырылды.






## Рәхмәт Сезгә, укытучыларыбыз!

Вакыт дигәнен тиз генә уза, сизелми дә. Без бүген чыгарылыш сыйныф укучылары. Мәктәп, укытучыларыбыз белән саубуллашабыз. Бүген аларга рәхмәт хисләрен җиткерәсе килә.

Хөрмәтле Римма апа!

Сез чын мәгънәсендә безнең якын кешебез булдыгыз! Сез каләм тотарга, язарга, хәреф танырга өйрәттегез. Шук-шаян, күзләре янып торган, уйлары уенда булган балаларны үзегезгә караттыгыз, тыңлаттыгыз. Безнең балачакны тагын да матур, алай гына түгел, эчтәлекле, файдалы да итә алдыгыз. Кеше өчен иң мөһим сыйфатларны өйрәттегез. Олыларны хөрмәтләргә, кечеләрне якларга, кеше белән исәнләшеп йөрергә, ярдәмчел булырга, теләсә нинди очракта кеше булып калырга өндәдегез.

Безнең тәртибебез һәм укуыбыз өчен борчылып йөрүче, һәр адымыбызны күзәтеп, ялгышлардан сакларга тырышучы сыйныф җитәкчебез – Ләйсән апа! Безнең киңәшчебез һәм сердәшчебез булдыгыз. Сезнең акыллы киңәшләрегезне, беркайчан да исегездән чыгармабыз. Күңелле аралашып, матур чаралар уздырдык, ул хәтирәләр күңелләрдә озак сакланыр.

Айсылу апа! Рәхмәт сезгә, иң авыр фән математиканың иң кирәкле икәнлеген аңлатып, тормышта куллана белергә өйрәткәнегез өчен, ныклы белем биргәнегез өчен. Тырышып тормышта үз сукмагыңны салырга кирәклеген өйрәткәнегез өчен.

Гөлнара апа! Рәхмәт сезгә, әдәби китаплар укып дөньяны танып белергә һәм үз фикереңне матур итеп җиткерә белергә өйрәткәнегез өчен. Әсәрләрдәге геройларның төрле язмышларына бәйләп, тормышта очраган катлаулы сорауларга җаваплар табарга өйрәткәнегез өчен.

Булат абый! Безнең егетләрнең сез яраткан укытучысы булдыгыз. Күп бәйге ярышларда катнаштык, матур җиңүләргә ирештек. Физик тәрбия бирүдә сез остаз укытучы, безнең сезгә булган хөрмәтебез зур. Барлык спорт төре буенча булган уңышларыбызда да сезнең өлешегез бар.

Сания апа! Сез матурлыкны күрә белергә, таный белергә өйрәттегез. Сезнең дәресләрдә, уңай һәм тискәре геройларның тормышын өйрәндек, төрле жанр әсәрләрен укыдык, тел байлыгыбызны арттырдык. Кешенең күңеле дә киеме дә, язуы яки почеркы да матур булсын диеп өйрәттегез.

Алия апа! Чит илдә яшәүче кешеләр теле ни өчен кирәк кешегә? Без бу сорауга күп тапкырлар җавап биреп, инглиз телен тырышып өйрәндек. Алган белемнәребез файдалы булсын, сезнең киләчәктә дә сәләтле укучыларыгыз күп булсын.

## Музейлар – халык хәтере

18 май –Халыкара музейлар көне .Ул 1977 нче елдан башлап билгеләп үтелә. Бу көнне музей күргәзмәләре һәркем өчен ачык була.

Безнең Әтнә районы музейлары шактый: Киме авылында С.Хәким, Комыргуҗа авылында Ш.Мәрҗани, Олы Әтнәдә Гатаулла бай йортында "Туган якны өйрәнү музее".

Безнең мәктәбебездә алар икәү: якташыбыз Самат Шакир һәм "Туган якны өйрәнү музее". Ә дусым авылында кечкенә генә булса да, Радик Фәизовның тормыш һәм иҗатына багышланган музей-бүлмә бар. Без ,7 сыйныф укучылары, мәктәбебездә эшләп килгән Самат Шакир һәм "Туган якны өйрәнү музее" әгъзалары. Музей материаллары белән танышып торабыз һәм төрле чараларда чыгыш ясыйбыз.

18 май көнне 2 нче сыйныф укучылары өчен Әтнә районы музейлары турында Садриева Алия апа презентация күрсәтеп, "Туган яны өйрәнү музее"на сәяхәт ясады. Музей экспонатлары белән таныштырды.Әлбәттә, без дә булыштык.

Мәйданы кечкенә булса да, анда бик күп борынгы әйберләр саклана: ирләр һәм хатын-кызларның борынгы киемнәре, бишек, чиккән һәм тукылган сөлгеләр. Шулай ук төрле хуҗалык кирәк-яраклары: сосккы, ипи көрәге, сырлы бәләк урын алган. Башка киштәләрдә тимер үтүкләр, керосин лампасы, төрле фонарьлар, урак, бизмән, агач савытлар урнаштырылган. Бер сүз белән әйткәндә, бу музей – халкыбыз хәзинәсенең кечкенә бер өлеше. Кайсы әйберләргә күз салсаң да, әби-бабаларыбыз тормышына килеп эләккән кебек буласың."Туган якны өйрәнү"музеендагы экспонатлар үткән заманда кулланышта булган әйберләрне, әби-бабаларыбызның яшәү рәвешен, тормыш-көнкүрешен предметлы итеп күрсәтә һәм шуның белән безнең күңелгә аеруча тирән тәэсир итә. Йөз тапкыр ишетүгә караганда бер тапкыр күрү яхшырак, дип юкка гына әйтмәгән ата-бабаларыбыз.

Музейларга ешрак йөрик, һәм үзебездә булган истәлекле борынгы әйберләрне музейларга тапшырыйк.

**7 нче сыйныф укучысы Галимҗанова Әдилә**



**Хөрмәтле укытучылар, кадерле балалар! Менә тагын бер уку елы артта калды. Без бик тырышып укыдык, белем тупладык. Төрле бәйгеләрдә, чараларда катнаштык. Призлы урыннар яуладык. Ел бик уңышлы һәм файдалы үтте. Укытучыларыгыз ярдәме белән бик күп үрләр яуланды. Рәхмәт аларга! Алда каникуллар. Сезгә рәхәтләнеп ял итәргә, көч тупларга һәм кабаттан яраткан мәктәбебезгә сәламәт булып килүегезне теләп калабыз. Сезне яраткан укытучыларыгыз янадан шатланып каршы алырлар, тыныч һәм күңелле яллар сезгә!**

Мәктәп директоры Хәмит абыйның дәресләрендә күп мәсьәләләр чиштек, табигать законнары өйрәндек. Физикада формулалар бик күп, тормышта да иң кирәкле формуланы табып дөрес итеп кулланырбыз.

Фәрдия апа! Сабыр булып, безне күпме кул эшләренә өйрәттегез, матур сәнгатьне дә якын күрдек, сездәй остазның шәкертләре булуыбызга без бик шатбыз. Иҗат чишмәгез саекмасын. Сезнең күргәзмәләр күпләрне сокландырсын.

Рәхмәт, барлык укытучыларга да. Мәктәп еллары күңелләрдә мәңге сакланыр. Укытучыларыбыз! Сезгә уңышлар юлдаш булсын, сәламәт булыгыз, мактаулы хезмәтегезнең матур нәтиҗәләрен күреп эшләгез.

**9 нчы сыйныф укучылары**

## Күңелле нәтиҗә!

"Булганнан барда була "-диләрме әле? Менә безнең турында инде бу мәкаль. Без, 8 нче сыйныф укучылары ,театр түгәрәгенә йөрүче укучылар 14 нче май көнне "Балачак" дип исемләнгән театраль куренеш куйдык. Аны без районыбыз мәктәпләре арасында үткәрелә торган отчет концертында күрсәттек. Ел буе уңышлы чыгыш ясаганыбыз, актив булганыбыз өчен безне мәктәбебез дирекциясе Әтнәдә урнашкан "Гатаулла бай" музеена театраль тамашага алып барды. Тамашада безгә милли киемнәр, экспонатлар, концерт номерлары һәм әлбәттә уеннар уйнаттылар. Чара бик күңелле үтте. Һәркем дә ошатты.

Димәк, һәр укучының да тырышлыгы үзенә уңай нәтиҗә бирә. Шуңа күрә һәрберебез тырышып укыйк, тәртипле һәм актив булыйк!

**8 нче сыйныф укучысы Зиганшина Зәмирә**



## Тиздән каникуллар!

Без тиздән 2 нче сыйныфны тәмамлыйбыз. Ел буена бик дус, тату яшәдек. Бу атнада походка барырга уйлыйбыз.Табигать кочагында күңелле итеп ял итәрбез.

Тиздән көтеп алган каникуллар башлана. Без, барыбыз да мәктәп яны лагеренда ял итәчәкбез. Анда дусларыбыз белән уйнарбыз, экскурсияләргә барырбыз. Җәйге ялыбыз файдалы һәм кызыклы булыр,дип уйлыйм.

**2 нче сыйныф укучысы Хакимов Риназ**